# THE FAMOUS TURKOLOGIST – ALTAICIST UZBEK BAICHURA

**Mustafa Öner,**
Ege University,
Turkey, 34100, Izmir, Bornova,
mustafa.oner@ege.edu.tr



**BAICHURA UZBEK SHARIFOVICH** (1923−1996) was a linguist and PhD (1966). After graduating from Kazan Institute of Law (1948) and Kazan Pedagogical Institute (1949) he worked at several higher educational institutions in Kazan. From 1953 to 1963, he worked at the Institute of Language, Literature and History of Kazan, a member institution of the USSR Academy of Sciences. From 1966 to 1971, he worked at the Institute of Language in Moscow. And from 1972, he worked at Leningrad University.

His works are devoted to the experimental phonetics of the Tatar language, with an emphasis on Turkic lexicon, Finno-Ugric studies,the Altai languages, etc.

**БАЙЧУРА ҮЗБӘК ШӘРИФ улы** (1923-1996) − тел галиме, филология фәннәре докторы (1966). Казан хокук (1948) һәм Казан педагогика (1949) институтларын тәмамлагач, Казанның югары уку йортларында эшли. 1953-1963 елларда СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1966-1971 елларда СССР ФАнең Тел белеме институтында (Мәскәү), 1972 елдан Ленинград университетында хезмәт куя.

Хезмәтләре татар теленең эксперименталь фонетикасына, төрки телләрдә сүз басымына, фин-угор һәм алтай телләрен өйрәнүгә һ.б. карый.

**БАЙЧУРА ҮЗБЕК ШАРИФОВИЧ** (1923-1996) − языковед, доктор филологических наук (1966). После окончания Казанского юридического (1948) и Казанского педагогического (1949) институтов работал в вузах Казани. В 1953-1963 в Институте языка, литературы и истории КФАН СССР, в 1966-1971 в Институте языкознания АН СССР (Москва), с 1972 в Ленинградском университете.

Труды по экспериментальной фонетике татарского языка, словесному ударению в тюркских языках, финно-угроведению, алтаистике и др.

Uzbek Baychura was born on October 6, 1923, in Kazan. His father, Baychura Sharifulla Husainovish, was a famous journalist and his mother, Alimback Amina Valievna, was a gynecologist. He grew up in an environment of respect for Tatar culture and literature and during his school years, he spoke Tatar exclusively. Political events of the time resulted in his father falling prey to repression in the mid-1930s. After having divorced her husband, his mother worked as a gynecologist for the family of the king of Saudi Arabia.

In 1940, after graduating from one of the best high schools, School №19, he entered university. Unfortunately, he suddenly fell ill and had to give up his studies. Before completely recovering, he was drafted into the army, but was released after two months from the corps. In 1948, he graduated from the Kazan Institute of Law. During his time of studying law, he also studied at the Faculty of Foreign languages of Kazan Pedagogical Institute from 1945 to 1949.

He was a postgraduate at the Institute of Language of the Academy of Science of the USSR, when E.V.Severotyan, a world-renowned scientist, was appointed his academic adviser. He completed a thesis "Vowels of the Tatar Literary Language in the Framework of Experimental Data". Heads of the Turkish sector of the Institute, N.K.Dmitriev and E.V.Severotyan, played a key role in his successful career.

In 1952, Y.Baychura was sent to Leningrad (now St. Petersburg) to complete his thesis on experimental phonetics. It was famous Russian scientist L.V.Shcherba, as well as associate professor M.I.Matusevich and their laboratory assistant I.B.Reitlenger, who founded experimental phonetics laboratory at Leningrad University and helped Baychura. In 1953, he completed his thesis, where he used L.Shcherba's applied methods of research.

One of the few laboratories of experimental phonetics in the world was organized by V.A.Bogorodisky at Kazan University. His work was continued by his disciples, one of whom was the world famous scientist Galimgan Sharaf and subsequently, after twenty years, also Baychura.

From 1954 to 1959, Baychura worked in the department of the Tatar language and literature at Kazan University, under the direction of Khatip Gosmanov. He worked with such linguists as L.Jalai, M.Z.Zakiev, and D.G.Tumasheva. During these five years he collected material on almost twenty languages and dialects using experimental phonetics and wrote a three volume thesis "The Sound System of the Tatar Language in Connection with Some Other Turkic and Finno-Ugric Languages". The thesis was published in two volumes (A Sound System of the Tatar Language: An Experimental and Phonetic Sketch, Part I, Kazan: Kazan University Publishing House, 1959, 398 p.; The Sound System of the Tatar Language in Connection with Some Other Turkic and Finno-Ugric Languages, Part II, Kazan, 1961, 392 p.).

One famous work by Baychura was the result of his laboratory work. Because of restrictions in the Kazan Experimental Laboratory, the young scientist had to continue a part of his calculations in the Experimental Phonetics Laboratory at Leningrad University and in the Laboratory of V.A.Artemyov at Moscow Pedagogical University of Foreign Languages. In this way he completed a unique thesis dedicated to Tatar phonetics, Finno-Ugric languages and Turkology.

In his work, the researcher looks into the vowels of the Tatar language. First he compared the acoustic and articulatory features of the Tatar language with other languages. His work also contained important material on vowel length in the Chuvash, Khakas, Azerbaijan, Turkmen and Kazakh languages. He compared the consonants of Tatar literary language and Tatar dialects with the phonemes of other languages. He also conducted detailed and novel analysis using radiographs and kimograms.

In phonetic studies, Baychura also used the material of the Turkic and Finno-Ugric peoples. He, therefore, came to the conclusion that the consonants of the Turkic languages of the Volga region and the Finno-Ugric languages of the Volga-Chulman (Kama) region had many common features.

In the second volume, methods of experimental phonetics (oscilloscope, spectrograph) were used and the obscurephonetic elements were revealed. The section about verbal accent stood out for its rich material and language comparison. He gave examples of the experimental verbal accents of the Kazakh, Uighur, Udmurt, Mari, Mordovian, and Khanty languages.

For five years in Kazan, Baychura performed experimental studies of the Tatar, Bashkort, Chuvash, Tuva, Udmurt languages. His other works were published in the form of articles in Ufa, Chaboksar, Leningrad, Budapest, Tallinn and other cities. Despite his great achievements, he was fired in 1959. Through the efforts of his father, he got a position at the Department of Lexicography and Terminology, founded by G.S.Amirov, at the Kazan member institute of the Institute of Language, Literature and History of the Academy of Sciences. There he wrote and edited dictionaries and soon thereafter, completed his doctoral thesis.

His doctoral thesis was appreciated by a lot of foreign and Russian researchers, with many reviews written by S.Murayama, S.Hattori (Tokyo) Fokos Fuchs (Budapest), Bohuslav Gala (Prague), B.A.Serebryannikov (Moscow), A.K.Borovkov (Leningrad), P.A.Ariste (Tallinn), M.S.Shiraliev (Baku) and others. His official opponents in the defense were Prof. P.Ariste (AS Estonia); Prof. A.K.Borovkov (AS USSR, Leningrad); Dr. E.V.Sevortyan (AS USSR, Moscow) and Dr. S.Visotsky (AS USSR, Moscow), all of whom appreciated his work highly.

Dr.Baychura began working in Leningrad, continuing to study Tatar under experimental methods (Some Phonetic Aspects of the Tatar Language/Works of Institute of Language, Literature and History of the Sciences Academy. Book II. Kazan, 1963, 127–140 pp. (in Tatar); Our Literary Language and Its Peculiarities. Kazan Utlary, 1969. No.1. 145–151 pp. (in Tatar). He studied stress and

intonation in the Turkic languages (On the Nature of Word Stress in the Chuvash Language (on kimographic records materials), Turkologic Study, Moscow-Leningrad, 1963. 41-57 pp. (in Russian).Other works include: Some Information about Word Stress in the Tuvan Language. Problems on Turkic and Oriental History. Kazan, 1964. 178-182 pp. (in Russian); Instrumental Phonetic Data on Intonation and Word Stress in the Turkic Languages. Proceedings of the Sixth International Congress of Phonetic Sciences. Prague 1967, Prague in 1970. 147-167 pp.; Some Experimental Data on the Melody of Speech and Word Stress in the Uighur Language Structure and History of the Turkic Languages. Moscow, 1971. 42-61 pp.) His work, published in 1971 in Baku, "Question of Emphasis in Turkish and Instrumental Information of Stress in Other Turkic Languages. Questions of Turkology. Proceedings of the Sixtieth Birthday of AS Azer. SSR M.S. Shiraliev. Baku, 1971. 188-195" is worth scientific attention . In this book he analyzed the problem of verbal accent in the Turkic languages.

The broadening of Baychura's research activities was observed in the 1970s. His articles (On Syllabic Structure of the Word in the Altaic Languages in Comparison with the Indo-European and Uralic Languages on Static and Instrumental Data/Sprache, Geschichte und Kulturder Altaischen Völker. Protokolband der XII. Tagung der Permanent International Altaistic Conference 1969 in Berlin, Schriftenzur Geschichte und Kultur des Alten Orients 5. Berlin 1974. 77−87) were devoted to the syllabic structure of the Ural-Altaic and Indo-European languages, which were based on static and instrumental data and other language data. The articles devoted to the ethnogenesis of the Kazan Tatars with respect to the ancient Bulgars were some of his most famous works (About the Bulgar Origin of the Kazan Tatars (the Language Basis). Ethnogenesis and the Ethnic History of the Turkic Peoples of Siberia and Adjacent Territories. Proceeding of the Regional Conferences. Omsk 1979. 262-267pp. (in Russian); Tataro-Bulgarica I: On the Bulgar Origin of the Qazan Tatars According to Some Linguistic Data/Studiaet Acta Orientalia 10, Bucarest 1980, 15-26; Tatarca-Bulgarca Bazı Dilbilim Verilerine Göre Kazan Tatarlarının Menşei / Türk Kültürü Araştırmaları XII.1−2. Ankara, 1984. 186−198 pp.). Dr. Baychura worked for five years in Leningrad and wrote 28 works there. In these works he discussed the methodology of experimental phonetics, phonetic problems of Turkic and other Altaic languages, the structure of terminology of these languages, the stress problems and cases in the Indo-European and Ural-Altaic languages.

Knowing the German and English languages, Baychura got in touch with other foreign scientists. He did not have a chance to go to Prague, where he was invited to an international conference. Despite this fact his article was published (Instrumental Phonetic Data According to the Intonation and Word Stress in the Turkic Languages/Proceedings of the Sixth International Congress of Phonetic Sciences. Prague 1967(1970).145−147) in 1967. In 1969 he also did not take part in the 12th International Altaicist Conference (PIAC) because he was not given the permit in spite of being ready to pay for his visit. Still, his article was published (On the Syllabic Structure of the Word in the Altaic Languages in Comparison with the Indo-European and Uralic languages on Static and Instrumental Data. Sprache, Geschichteund Kulturder Altaischen Völker. Protokolband der XII. Tagung der Permanent International Altaistic Conference 1969 in Berlin, Schriftenzur Geschichte und Kultur des Alten Orients 5. Berlin 1974. 77−87).

He was fired from his post in March 26, 1971. As he wrote in his autobiography, *"So, my work at the Institute of Linguistics came to an end when the Institute said that my thesis was not worthy of acceptance in 1962, but I successfully defended it in another republic in 1996. They didn't value my work, but in spite of this, my articles were published and received welcome in fifteen countries throughout Asia, Europe and America. For example: reviews of my works were written by N.Poppe, G.Doerfer, S.Murayama, and O.Pritsak; my speeches at the phonetic conference in Florida (USA, 1977) and 4th Congress of Phonetics (Japan, 1983) were considered excellent".*

When he was 60 years old, in 1983, he did not have a pension because he had been dismissed in 1971. During his retirement, he wrote about one hundred scientific papers and all of them have been translated into foreign languages. Despite his being invited specifically to foreign scientific organization conferences, he did not get permission to leave the country. The Phonetic Society of Japan in 1976 and the Ural-Altaic Society in 1989 invited him to the Finno-Ugric Symposium in Hamburg, but he could not take part in any of them. Despite this, Baychura is one of the best Altaic Turkologists. Even if he had a more difficult destiny than others, he was recognized by such scientists as A.N.Kononov, N.Baskakov, K.Musaev, and E.R.Tenishev. He devoted all his life to the research of the Ural-Altaic languages. In addition to the international conferences, symposia, papers, which were published as congressional library materials, he was also one of the most active and regular founders of and contributors to such journals

as *Acta Linguistica Academiae Scientiarum Hungaricae* (Budapest); *Acta Universitatis Carolinae Philologica* (Praga); *Annali del Seminario di Studidell'Europa Orientale* (Napoli-Roma); *Archív Orientální* (Praha); *Artura Ozola Diena* (Riga); *Bulletin of the Phonetic Society of Japan* (Tokio); *Central Asiatic Journal* (Wiesbaden); *Études Finno-Ougrienne* (Paris-Budapest); *Finnisch-Ugrische Forschungen* (Helsinki); *Finnisch-Ugrische Mitteilungen* (Hamburg); *International Review of Slavic Linguistics* (Edmonton); *Journal of Turkish Studies* (Harvard University); *Lingua Posnaniensis* (Poznan); *Materialia Turcica* (Bochum); *Oriens* (Leiden); *Orientalia Suecana* (Uppsala-Stockholm); *Rocznik Orientalistyczny* (Warszwa); *Series Euroasiatica* (Napoli-Pisa); *Studia et Acta Orientalia* (Bucarest); *Study of Sounds* (Tokio); *The Bulletin of the Phonetic Society of Japan* (Tokio); *Ural-Altaische Jahrbücher* (Göttingen); *Wiener Zeitschriftfür die Kunde des Morgenlandes* (Wien); *Zeitschriftfür Dialektologie und Linguistik* (Wiesbaden).

The Tatar scientist, Altaic Turkologist, Uzbek Baychura died on March 12, 1996. He was never recognized as a great philologist during his life, but the Tatar people and future generations have the right to be proud of the legacy left by this outstanding scientist.

**References**


1. OnerM. Üzbek Ş. Bayçura (Hayatı veEserleri Üzerine) //Ege Üniversitesi Türk Dilive Edebiyatı Araştırmaları Dergisi. İzmir, 2001, 1-44 b.
2. Tatarskiy entsiklopedicheskiy slovar'. Kazan', 1999. S.58. (in Russian).


---

# ТАНЫЛГАН ТЮРКОЛОГ-АЛТАИСТ ҮЗБӘК БАЙЧУРА


**Мостафа Өнәр,**
Эгей университеты,
Төркия, 34500, Борнова, Измир,
mustafa.oner@ege.edu.tr


Үзбәк Байчура 1923 елның 6 октябрендә Казанда туган. Әтисе – танылган журналист, язучы Шәрифулла Хөсәен улы Байчура, әнисе – табиб-гинеколог Әминә Вәли кызы Алимбәк. Байчура татар мәдәниятен һәм әдәбиятын хөрмәт иткән иҗтимагый даирәдә үсә һәм мәктәп чорына кадәр татарча гына сөйләшә. 1940 елда заманының иң алдынгы уку үзәкләренең берсе саналган 19 нчы мәктәпне тәмамлагач, университетка керә, ләкин көтмәгәндә авырып китеп, укуын туктатырга мәҗбүр була. 1942 елда, әле ныклап аякка да басмаган килеш, армиягә чакырыла, ләкин ике айдан соң хәрби хезмәттән азат ителә.

Байчура 1942-1948 елларда Казан хокук институтын экстерн рәвештә тәмамлый. Бер үк вакытта (1945-1949) Казан педагогика институтының чит телләр факультетында белем ала. Әтисе 30 нчы еллар уртасында репрессияләнгәннән соң, әнисе аннан аерыла һәм 1935-1937 елларда Согуд Гарәбстанында король гаиләсендә хатын-кызлар табибы булып эшли.

Ү.Байчура Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясе Тел белеме институтына аспирантурага кабул ителгәч, аның фәнни җитәкчесе итеп халыкара танылган галим Е.В. Севортян билгеләнә. «Гласные татарского литературного языка в свете экспериментальных данных» дигән темага диссертация яза. Институтның төрки секторын җитәкләгән СССР Фәннәр академиясе әгъзасы Н.К.Дмитриев һәм Э.В.Севортян Ү.Байчураның карьера үсешенә уңай йогынты ясыйлар.

1952 елда Ү.Байчура, эксперименталь фонетикага багышланган диссертациясен эшләү өчен, Ленинградка (хәзерге Санкт-Петербург) җибәрелә. Ленинград университетының эксперименталь фонетика лабораториясенә нигез салган, рус фонетикасының танылган белгече Л.В.Щерба, доцент М.И.Матусевич, Л.Р.Зиндер, лаборант И.Б.Рейтлингер кебек белгечләр аңа һәрвакыт ярдәм итәләр. 1953 елны Ү.Байчура Л.Щербаның фәнни тәгълиматларына нигезләнеп язылган хезмәтен тәмамлый.

Дөньядагы эксперименталь фонетика лабораторияләренең берсе В.А.Богородицкий тарафыннан Казан университетында корыла; соңрак бу эшне аның укучысы, фән дөньясында танылган галим Галимҗан Шәрәф дәвам итә. Егерме елдан соң өченче белгеч – Ү.Байчура килә.

1954-1959 елларда Ү.Байчура Казан университетында Хатыйп Госманов җитәкләгән татар теле һәм әдәбияты кафедрасында

Л.Җәләй, М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева кебек тел белгечләре белән бергә эшли. Ул биш ел эчендә егермегә якын телнең һәм диалектларның эксперименталь фонетика материалларын җыя һәм «Звуковой строй татарского языка в связи с некоторыми другими тюркскими и финно-угорскими языками» дигән өчтомлык диссертациясен яза, һәм ул китап рәвешендә ике томда басылып чыга (Звуковой строй татарского языка: экспериментально-фонетический очерк. Часть I, Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1959, 398 с.; Звуковой строй татарского языка в связи с некоторыми другими тюркскими и финно-угорскими языками. Часть II, Казань, 1961, 392 с.).

Ү.Байчураның хезмәте күп еллар буе ясалган лаборатория тәҗрибәләренең нәтиҗәсе була. Яшь галим, Казандагы эксперименталь лабораториянең мөмкинлекләре җитмәгәнгә, үлчәү-теркәүләренең бер өлешен Ленинград дәүләт университетының Эксперименталь фонетика лабораториясендә һәм Мәскәү дәүләт чит телләр пединститутында В.А.Артемов лабораториясендә башкара.

Галим бу хезмәтендә татар теленең сузыклар системасын җентекләп өйрәнеп чыга. Татар сузыкларының акустик һәм артикуляция үзенчәлекләрен беренче тапкыр башка телләр белән чагыштырып тикшерә. Чуваш, хакас, әзербайҗан, төрекмән һәм казах телләрендәге сузыкларның озынлыклары турында аерым бүлекләрдә гаять бай материал бирә. Татар әдәби телендәге һәм диалектларындагы тартыкларны башка телләрнең фонемалары белән чагыштыра. Китапның ахырында бик кыйммәтле кушымта (ренгенограмнар һәм кимограммалар) тәкъдим итә.

Ү.Байчура, фонетиканы тикшергәндә, татар теле белән генә чикләнми, күрше төбәкләрдәге төрки һәм угро-фин халыкларыннан да материал туплый. Шулай итеп ул элегрәк игътибар ителмәгән нәтиҗәгә килә: Идел буе төрки телләрнең консонантизмы белән Идел-Чулман угро-фин телләренең консонантизмы арасында бик күп уртак үзенчәлекләр сакланган.

Китапның икенче томында эксперименталь фонетиканың алдынгырак методларыннан да файдаланыла (осциллография, спектография); нәтиҗәдә, авторның күзәтүләре югарырак дәрәҗәгә күтәрелә. Китапның сүз басымына караган өлеше материал байлыгы һәм чагыштырылган телләрнең күплеге белән аерылып тора, монда казах, уйгур, удмурт, мари, мордва, ханты телләренең сүз басымы турында эксперименталь белемнәр бирелә.

Ү.Байчура Казанда биш ел эчендә татар, башкорт, чуваш, тува, удмурт телләре буенча эксперименталь тикшерүләр ясый, башкарган хезмәтенең нәтиҗәләре Казан университетыннан читтә, Уфа, Чабаксар, Ленинград, Будапешт, Таллин шәһәрләрендә мәкалә булып басыла. Шуңа да карамастан Ү.Байчура 1959 ел ахырында эштән җибәрелә. Әтисенең ярдәме белән Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында Г.С.Әмиров ачкан лексикография-терминология бүлегенә эшкә урнаша. Ул сүзлекләр әзерләү һәм редакцияләү белән шөгыльләнә, докторлык диссертациясен тәмамлый.

Аның докторлык диссертациясенә чит илләрнең һәм илебезнең бик күп галимнәре хуплап рецензияләр яза: Ш.Мураяма, Ш.Хаттори (Токио), Фокос Фукс (Будапешт), Богуслав Гала (Прага), Б.А.Серебренников (Мәскәү), А.К.Боровков (Ленинград), П.А.Аристе (Таллин), М.Ш.Ширалиев (Баку) һ.б. Рәсми оппонентлар итеп проф. П.Аристе (Эстония ФА); проф. А.К.Боровков (СССР ФА, Ленинград); доктор Е.В.Севортян (СССР ФА, Мәскәү); доктор С.Висоцкий (СССР ФА, Мәскәү) билгеләнә, алар хезмәтне уңай бәялиләр.

Казаннан китеп, Ленинградта эшли башлаганнан соң да, Ү.Ш.Байчура татар телен эксперименталь методлар белән тикшеренүне дәвам итә (кара: Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре / СССР Фәннәр Акад. Казан фил. Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәтләре. Икенче китап. Казан, 1963. 127-140; Әдәби телебез һәм яңа лингвистик ысуллар // Казан утлары, 1969. №1. 145-151), төрле төрки телләрдәге басым һәм интонация мәсьәләләрен өйрәнә (кара: К вопросу о характере словесного ударения в чувашском языке (по материалам кимографических записей) // Тюркологические исследования. Москва–Ленинград, 1963. 41-57; Некоторые данные о словесном ударении в тувинском языке // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. Казань, 1964. 178-182; Инструментально-фонетические данные относительно интонации и словесного ударения в тюркских языках // Proceedings of the Sixth International Congress of Phonetic Sciences. Prague 1967, Прага 1970. 147-167; Некоторые экспериментальные данные о мелодике речи и словесного ударения в уйгурском языке / Структура и история тюркских языков. Москва, 1971. 42-61).

Аның 1971 елда Бакуда басылган «К вопросу об акценте в турецком и инструментальные данные об ударении в других тюркских языках» (Вопросы тюркологии. К шестидесятилетию академика АН Азер. ССР М.Ш. Ширалиева. Баку, 1971. 188-195) дигән хезмәте бигрәк тә игътибарга лаек. Монда төрки телләрдәге сүз басымы проблемасы анализлана.

Ү.Байчураның җитмешенче елларда тикшерү офыклары киңәя бара. Урал-алтай һәм һинд-европа телләренең иҗек корылышын статистик һәм инструменталь материалга таянып чагыштырган мәкаләсе (О слоговой структуре слова в алтайских языках сравнительно с уральскими и индоевропейскими по статическим и инструментальным данным // Sprache, Geschichte und Kultur der Altaischen Völker. Protokolband der XII. Tagung der Permanent International Altaistic Conference 1969 in Berlin, Schriften zur Geschichte und Kultur des Alten Orients 5. Berlin 1974. 77-87) тел материалларына нигезләнгән; Казан татарлары этногенезында борынгы болгарларга мөнәсәбәтен яктырткан мәкаләләре (О булгарском происхождении казанских татар (по данным языка) / Этногенез и этническая история тюркоязычных народов Сибири и сопредельных территорий. Тезисы докладов областной конференции, Омский университет. Омск 1979. 262-267; Tataro-Bulgarica I: On the Bulgar Origin of the Qazan Tatars According to Some Linguistic Data / Studia et Acta Orientalia 10, Bucarest 1980, 15-26; Tatarca-Bulgarca Bazı Dilbilim Verilerine Göre Kazan Tatarlarının Menşei / Türk Kültürü Araştırmaları XII. 1–2. Ankara, 1984. 186-198) шул киңлекне күрсәтә.

Ү.Байчура Ленинградтагы тел белеме институтында биш ел эшләү дәвамында 28 хезмәт яза. Аларда галимнең төп белгечлеге булган эксперименталь фонетика методологиясеннән башлап, төрки телләрнең һәм башка алтай телләренең фонетик проблемалары, бу телләрдә терминологияне кору, һинд-европа һәм урал-алтай телләрендә килеш һәм басым проблемаларына бәйле темаларда эшләгәне күренә.

Алман һәм инглиз телләрен белгән Ү.Байчура чит илләрдәге хезмәттәшләре белән тыгыз элемтәдә булган. 1967 елда Прагада булган Халыкара конференциягә җибәрмәсәләр дә, аның чыгышы басылып чыга (Инструментально-фонетические данные относительно интонации и словесного ударения в тюркских языках // Proceedings of the Sixth International Congress of Phonetic Sciences. Prague 1967 (1970). 145-147). Алтаистларның 1969 елда узган XII Халыкара конференциясенә (PIAC) аңа шулай ук катнашырга рөхсәт бирелми, чыгышы гына дөнья күрә (О слоговой структуре слова в алтайских языках сравнительно с уральскими и индоевропейскими по статическим и инструментальным данным // Sprache, Geschichte und Kultur der Altaischen Völker. Protokolband der XII. Tagung der Permanent International Altaistic Conference 1969 in Berlin, Schriften zur Geschichte und Kultur des Alten Orients 5. Berlin 1974. 77-87).

Ү.Байчура 1971 елның 26 мартында эштән алына. Татар галиме үз автобиографиясендә болай дип яза: «...шулай итеп, минем Тел белеме институтындагы эшем бетте. Бу институт 1962 елда докторлык диссертациямне хаксыз рәвештә кире какты; шул ук диссертацияне 1966 елда башка бер республикада уңышлы рәвештә яқладым. Тел белеме институты минем хезмәтләремне уңышсыз дип кабул итте, ә алар Азия, Европа һәм Американың унбиш илендә басылып чыкты, халыкара гыйльми үзәкләрдә хуплап каршы алынды. Мәсәлән, хезмәтләре бөтен дөньяда нәшер ителгән Н.Поппе, Г.Доерфер, Ш.Мураяма, О.Прицак кебек тел галимнәренең рецензияләре; Флоридадагы фонетика конференциясе (АКШ, 1977) һәм IV фонетистлар конгрессы (Япония, 1983) кебек халыкара җыеннарда һаман югары дәрәҗәдә каршы алындылар».

Ү.Байчура 1971 елдан эшсез калган, 1983 елда алтмыш яше тулса да, дәүләттә эшләү вакытын үтәмәгән дип, аңа пенсия дә бирелмәгән. Галим шул вакыт эчендә йөзгә якын гыйльми хезмәт язган, алар барысы да чит илләрдә басылган. Чит илләрдәге гыйльми оешмалардан махсус чакырулар булса да, аңа читкә чыгарга рөхсәт бирелмәгән. Мәсәлән, 1976 елда Япония фонетика җәмгыяте, 1989 елда урал-алтай җәмгыяте Гамбургка фин-угор телләре симпозиумына чакырган, ләкин анда да чыгармаганнар. Шуңа да карамастан, Ү.Байчура СССР шартларында дөньяда иң алдынгы алтаист тюркологларның берсе булды. Башкалар белән чагыштырганда, бик авыр тормыш шартларында яшәсә дә, аны А.Н.Кононов, Н.Баскаков, К.Мусаев, Е.Р.Тенишев кебек галимнәр, фән дөньясы таныган. Ул урал-алтай телләренә, тел белеменә хезмәт иткән алдынгы совет тюркологы иде. Халыкара конференция,

симпозиум, конгресс материаллары буларак басылган хезмәтләреннән тыш, тел белеме, тюркология, алтай телләренә багышланган Acta Linguistica Academiae Scientiarum Hungaricae (Budapest); Acta Universitatis Carolinae Philologica (Praga); Annali del Seminario di Studi dell'Europa Orientale (Napoli-Roma); Archív Orientální (Praha); Artura Ozola Diena (Riga); Bulletin of the Phonetic Society of Japan (Tokio); Central Asiatic Journal (Wiesbaden); Études Finno-Ougrienne (Paris-Budapest); Finnisch-Ugrische Forschungen (Helsinki); Finnisch-Ugrische Mitteilungen (Hamburg); International Review of Slavic Linguistics (Edmonton); Journal of Turkish Studies (Harvard University); Lingua Posnaniensis (Poznan); Materialia Turcica (Bochum); Oriens (Leiden); Orientalia Suecana (Uppsala-Stockholm); Rocznik Orientalistyczny (Warszwa); Series Euroasiatica (Napoli-Pisa); Studia et Acta Orientalia (Bucarest); Study of Sounds (Tokio); The Bulletin of the Phonetic Society of Japan (Tokio); Ural-Altaische Jahrbücher (Göttingen); Wiener Zeitschrift für die Kunde des Morgenlandes (Wien); Zeitschrift für Dialektologie und Linguistik (Wiesbaden) журналларында Ү.Байчура даими автор буларак катнаша.

Зур татар галиме, тюрколог-алтаист доктор Үзбәк Байчура 1996 елның 12 мартында вафат була. Ул исән чагында үз илендә җитәрлек танылмады. Әмма татар халкының бүгенге һәм киләчәк буыннары бу асыл затның кешелек мирасына керткән өлеше белән горурланырга хаклы.

**Әдәбият**


1. *Oner M.* Üzbek Ş. Bayçura (Hayatı ve Eserleri Üzerine) //Ege Üniversitesi Türk Dili ve Edebiyatı Araştırmaları Dergisi. İzmir, 2001, 1-44 b.
2. Татарский энциклопедический словарь. Казань, 1999. С.58.